МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

13.11.2025 Казан ш. 4143-р

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендәге газ бүлгеч челтәр объектларының саклау зонасын билгеләү турында.

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ хатын исәпкә алып (01.11.2025 № 01А-08/2335) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан 6326,9 м озынлыктагы һәм гомуми мәйданы 26244 +/- 57 кв.м территорияне тәшкил иткән 16:15:000000:2126, 16:15:000000:2262, 16:15:000000:3066, 16:15:000000:3792, 16:15:000000:3881, 16:15:040701:528, 16:15:150201:2386, 16:15:030301:383, 16:15:090101:1668, 16:15:000000:3853 кадастр номерлы, 74810, 75105, 75111, 75171, 75193, 75293 инвентарь номерлы газ бүлгеч челтәр объектларының саклау зонасын территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасы, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп билгеләргә (бастырып чыгару каралмаган).

2. Газ бүлгеч челтәр объектларының эксплуатацияләү срогында газүткәргечнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**